КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге составына керүче Пүкәл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.10.2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2020 елның 28 октябрендә узган гражданнар җыенында «2021 нче елда Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге Пүкәл торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге составына керүче Пүкәл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1100,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Пүкәл авылында балалар мәйданчыгы тозү;
- Пүкәл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 145 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 95 кеше тавыш бирүдә катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 95 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге составына керүче Пүкәл торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
2. «2021 нче елда Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге Пүкәл торак пунктында Саба муниципаль районы Әзмә авыл җирлеге составына керүче Пүкәл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1100,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә” һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

1) Пүкәл авылында балалар мәйданчыгы тозү;
2) Пүкәл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

карарын кабул ителгән дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru

адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Эзмә авыл
җирлеге башлыгы — А.Р.Шәйхетдинов